
وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!


# Дин вә Мәгыйшәт

№3 (100). 2 сентябрь 2011 / 04-шәүвәл-1432

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Хәерле сәгатьтә! ▷2◁



Ренат БЕККИН белән әңгәмә ▷2-3◁



Җиләк-җимеш турында кызыклы мәгълүматлар ▷4◁

## Бәйрәмнәр мөбарәк булсын!

***Һәр нәрсә Аллаһның тәкъдире белән эшләнелә. Быел Ураза бәйрәменең 30 августка туры килүендә дә Аллаһы Тәгаләнең бер хикмәте бардыр дип уйлыйбыз. Республика көнендә искиткеч зур проектларны ачу тантаналары үтте. Диннең һәм дөньяви бәйрәмнең бергә килүе – ул үзе бер хикмәт, чөнки безнең татар халкында, гомумән башка мөселманнарга караганда, интеллектуаль ислам хөкем сөрә. Нииндидер бер хисси ислам да түгел, нииндидер бер кыргыйлык та түгел. Бездә дөньяны да, динне дә бертигез алып баруның күркәм мисаллары бар. Быелгы Рамазанның тагын бер зур хикмәтен әйтеп китмичә булдыра алмыйм: Аллаһның рәхмәте белән ураза бөтен дөньяда да бер көндә башланып китте. Бу бик сирәк була торган күренеш. Ислам дөньясының бердәмлек күрсәткече дип әйтер идем мин моны.***



Августның соңгы көннәрендә тагын бер әһәмиятле тарихи вакыйга булды – Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашлыгында "Мәрҗани" мәчетендә Ураза гаете үтте. Казан ханлыгы җимерелгәннән соң рәсми рөхсәт нигезендә башкалада беренче булып корылган, дингә каршы сәясәт алып барылган заманнарда – совет чорында да ишекләре ябылмаган тарихи мәчет халыкны яңа чыгып килүче кояш нурларына күмелеп каршы алды. Халык бирегә иртәнге дүрттән җыела башлаган иде инде. Иман йорты эченә сыймаганнар намазларын ишегалдында һәм урамда укыды. Татарстанның дәүләт башлыгы бәйрәм намазында катнашты, мондый вакыйганың 1552 елдан – Казан ханлыгы таркалганнан бирле, ягъни инде 459 ел күзәтелгәне юк иде. Республикабызда моңа кадәр югары дәрәҗәдәге җитәкчеләрнең дини бәйрәмнәргә гыйбадәт өчен йөргәннәре күзәтелмәде. Президент белән "Мәрҗани" мәчетенә Казан мэры Илсур Метшин, Төркиянең Казандагы консулы Әхмәт Акынты, шәһәр мэриясенең күпсанлы хезмәткәрләре, президент аппаратының дини оешмалар белән эшләү идарәсе җитәкчесе Марат Гатин килде.

"Татарстан – Яңа гасыр" телеканалында "Мәрҗани" мәчетеннән турыдан-туры трансляция оештырылды. Туры эфир иртәнге сәгать җиде туларга ун минутта башланып, бер сәгать тирәсе барды. Дини һәм дөньяви бәйрәмнәр эстафетасын Белем көне кабул итеп алды. Монысы – бөтен ил өчен дә уртак бәйрәм булуы белән үзенчәлекле.

XXI гасыр – җәмгыятебезнең гаять тә катлаулы чоры. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән барлык мәктәп укучыларын, студентларны, ата-аналарны, укытучыларны, гомумән, һәркемне олуг бәйрәм – Белем көне белән тәбрик итәсем килә. 1 сентябрь – белем туплаудагы яңа этап. Әлеге көн, мәктәп һәм башка уку йортларында белем алучылар өчен генә түгел, яңа буын тәрбиясен кайгырткан һәркайсыбыз өчен дә мөһим вакыйга. Шуңа да бүгенге көндә бары тирән гыйлемгә ия булганнар гына тормышта үз юлларын таба ала, бары гыйлемле кешеләр генә уңышка ирешә, бары гыйлемле яшьләргә генә милләтнең, мөселман өммәтенең киләчәген ышанып тапшыра алабыз.

Татар халкында юкка гына "Гыйлемне бишектән алып ләхеткәчә алыгыз" дип әйтмиләр. Мәгариф системасы халкыбыз, милләтебез, динебез тарихында элек-электән әһәмиятле өлкәләрнең берсе булып килде. Халкыбызның йөзен һәрвакытта та гыйлемле зыялылар билгеләде. Шул исәптән, дини һәм дөньяви гыйлемне бергә үреп алып бардылар. Пәйгамбәребез (с.г.в.) дә: "Гыйлем алу мөэмин мөселманнар өчен фарыз гамәл", – дигән.

Әйдәгез, бергәләшеп үзебезнең киләчәк тарихыбызны язуга өлеш кертик, гыйлемле, инсафлы кавем тәрбиялик. Милләтебез тарихын югары гыйлемгә ия булган зыялы аксакаллар билгеләсә, киләчәгебез үз эшләренең белгечләре булган гыйлемле яңа буын кулында.

Хәерле елларда һәркайсыбызга да файдалы гыйлемнәр генә насыйп булсын!

**Үзәкләшкән дини оешма – ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ**

## Мөселман яшьләре БЕСЛАН корбаннарын искә алачак

**Бишенче сентябрьдә Казанда "Ислам дине террорчылыкка каршы" дип исемләнгән митинг узачак.**

Үткәрелү урыны итеп Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетының төп бинасы каршындагы мәйдан сайланган. Митинг 11:00 сәгатьтә башланып китәр, дип көтелә. Әлеге чара 2004 елда мәктәп укучылары, укытучылар һәм ата-аналар тоткын итеп алынган Беслан трагедиясенә багышлана.

Урам җыенының төп максаты – җәмәгатьчелекнең, бигрәк тә яшьләрнең игътибарын экстремизм, террорчылык проблемаларына җәлеп итү, бу замана чирләренә каршы тору өчен төрле милләт һәм дин яшьләрен берләштерү. Әлеге коточкыч явызлыкны кылучылар, үзләрен Аллаһ юлында хезмәт итүче мөселман өммәтеннән дип белдереп, ислам диненә тап төшерде. Динебездә кеше үтерү – иң зур гөнаһларның берсе. Үткәреләчәк акция дә кешеләргә ислам диненең җәмгыятьтә толерантлык урнаштыручы, рухи кыйммәтләрне таратучы тынычлык дине булуына төшендерүдән гыйбарәт булыр дип көтелә.


Исегезгә төшерәбез: 2004 елгы Беслан фаҗигасендә 335 кеше (шуларның 186 балалар!) һәлак булды, сигез йөздән артык кеше тән җәрәхәтләре алган иде.

**Айнур СОЛТАНОВ, Үзәкләшкән дини оешма – ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең яшьләр белән эшләү бүлеге җитәкчесе**

## ХӘЕРЕҢ БЕЛӘН, ШӘҮВӘЛ АЕ

**Һиҗри календарьда изге Рамазан аен шәүвәл ае алыштыра. Бу айның беренче көнендә без Ураза бәйрәмен билгеләп үттек...**

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) әйткән: "Рамазан уразасыннан соң шәүвәл аенда алты көн ураза – тотучыга тулы ел дәвамында ураза тоткан кебек савап булыр, чөнки безнең шәригатебездә бер изгелеккә ун өлеш саваптан ким булмас. Исәпләсәк утыз көнгә өч йөз, алты көнгә алтмыш көн ураза булыр." Дәхи Рәсүлуллаһ әйтә: "Бер кеше Рамазаннан соң шәүвәл аенда алты көн ураза тотса, Аллаһы Тәгалә бу кешенең тәнен тәмугка хәрам кылыр. Һәр көне бәрабәренә кырык шәһид (сугышта шәһид булган сәхабәләр) савабын бирер, һәр көне бәрабәренә бу кеше өч оҗмахта бер шәһәр бина кылырлар".



Без Сезгә бу шәүвәл ае хакында, аның кодрәте, бу айда кыла торган гыйбадәтләр хакында бераз аңлатып үтәбез.

1890 елда Санкт-Петербургта басылып чыккан "Хуләсәтүл-мәсәилә үә мүһиммәтүл-дәләил" китабының туксан алтынчы битендә шәүвәл ае тарихы языла.

Башка айлар кебек үк бу айның да исеме гарәп падишаһларының исеме белән бәйле. Бәни Гайсә кабиләсенең Әнүш исемле падишаһы була. Ул гомеренең күбрәк өлешен сахраларда, урманнарда йөреп, төрле бөҗәкләрне, аларның тән төзелешен өйрәнеп уздыра торган була. Һәрбер хакимдә була торган үзенә бертөрле сәерлек Әнүш падишаһта да була. Ул гомере буе диңгез буенда яшәргә тиешле кигәвен зурлыгындагы яшел чебен эзли... Көннәрдән беркөнне, кояш баегач, диңгез буенда нәкъ шул чебеннәрнең өерен күрә һәм гаҗәпләнеп кычкырып җибәрә: "Мә һәзәл шәүвәләте", ягъни "Бу нинди ачыш!" мәгънәсендә. Бу – ул вакытта "туван" дип аталган айның ахыргы көне була һәм Әнүш падишаһ бу айны шушы ачыш хөрмәтенә "шәүвәл" дип атый. Ислам дине кергәнче, шәүвәлнең беренче көне гарәпләрдә нәхес, ягъни бәхетсезлек, шомлылык, уңышсызлык көне дип исәпләнелгән.

Гарәп ярымутравына ислам дине кергәч, шәүвәлнең беренче көне Гайделфитыр көне, ягъни Рамазан уразасы тәмам булганнан соң бәйрәм ителә торган Ураза гаете булды. Без хәзер шушы изге айга керештек. Рәсүлебез (с.г.в.) бик күп хәдисләрдә шушы айның фазыйләтләре хакында безгә аңлатты. Өммәтебезгә нәсыйхәт кылып, Рамазан аенда яшәгән гомеребезнең, кадерле тормышыбызның тагын да дәвамы булсын өчен, гамәлләребез тагын да ихлас булсын өчен, шушы шәүвәл аенда өстебезгә тагын бер гыйбадәтне йөкләде. Барча мөселман өммәтен дә Рамазан аенда тоткан ураза кебек, шулай ук шәүвәл аенда да алты көн ураза тотып уздырырга тиешле. Бу, әлбәттә, өстебезгә йөкләтелгән фарыз, вәҗеб гыйбадәт үк булмаса да, мәгәр безнең иманыбызның Рамазан аенда пакьләнүе, җаныбызның, тәнебезнең сафлануы тагын да дәвам итү өчен зур мөмкинчелек бу. Хәтта рәсүлебез (с.г.в.) бер хәдисендә: "Шәүвәл аенда алты көн тоткан уразасына кеше дөньяга килгән сабый бала кебек гөнаһсыз булыр", – диде. Бала дөньяга килгәндә беләбез, гөнаһсыз булып туа. Шулай ук кеше дә Рамазан уразасын тотканнан соң, шәүвәл аенда да алты көн ураза тотып уздырса, гөнаһсыз бала кебек калыр, ди. Ягъни, барча гөнаһларын Аллаһ Раббыбыз гафу кылырмын, ди. Бу – безгә зур шатлык, зур сөенеч. Рамазан аенда тоткан уразабыздан каффәрәт, тагын да зур сөенечкә ирешү өчен зур мөмкинчелек бирелде.

**(Ахыры 3 нче биттә.)**

# Хәерле сәгатьтә!

**"Балагызны ни өчен татар мәктәбенә бирмисез?" – дигән сорауга ата-аналар еш кына: "Безнең балабыз татар телен болай да әйбәт белә", – дип җавап бирә. Сөйләшү барышында шул ачыклана: алар халкыбыз язмышы өчен борчылмый, аның киләчәге турында уйланмый, аның дәүләтчелеген саклауга битарафлык күрсәтә.**



Икенче төрле әйткәндә, дәүләтебез (мин татар халкының дәүләтен күз уңында тотам) алдында гражданлык бурычы, ә ата-бабалары алдында нәсел җаваплылыгы тоймыйлар, татар халкына каршы алып барыла торган дошман идеологиясе агымына буйсынып гомер уздыралар. Ә бит халкыбызны, аның гасырлар дәвамында әхлакый иләктән иләнеп безгә килеп җиткән асыл сыйфатларын саклар өчен, татар телен әйбәт белү генә җитми, аның өчен җаныбыз-тәнебез белән чын татар кешесе булуыбыз кирәк. Махсус уку йортларында укып, мәсәлән, француз телендә чын француз кешесе кебек оста сөйләшергә өйрәнеп була, андый кешеләр күп. Тик аңа карап кына чын французга әйләнергә мөмкин түгел. Чөнки француз булу өчен, тәнеңдә-җаныңда француз рухы яшәве кирәк. Һәм шулай ук чын татар кешесе булу өчен дә татар рухына ия булу зарур. Ә ул рухка гаиләдә моңлы бишек җырлары, туган тел аһәңе, тылсымлы халык әкиятләре аша нигез салына. Аннары ул рух милли ясле-бакчаларда ныгытыла, соңыннан, милли мәктәпләрдә гыйлем алганда, тәмам формалашып җитә.

Милли мәктәпләрдә уку программасын үзләштергәндә бала, үзенең ата-бабаларында меңнәрчә еллар билгеле бер юнәлештә үскән аңасты (подсознание) һәм геннарына яраклы рәвештә, халкының тарихын, мәдәниятен, әдәбиятын өйрәнә, аның олуг шәхесләре белән тирәнтен таныша, аларның фидакарь тормышларыннан үрнәк ала, милләте тарихындагы гыйбрәтле хәлләрне белә, шул вакыйгалар һәм аларның сәбәпләре турында уйлана, халкы язмышындагы фаҗигаләргә кагылышлы драматик мизгелләр кичерә… Милли мәктәптә ул үзенең туган мохитендә кайный, милли яктан беркемнән дә кимсетү кичерми, тулысынча үз халкына бирелгән шәхес булып үсеп җитә.

Ә рус мәктәбендә укучы татар баласы турында мондый сүзләр әйтеп буламы? Һич тә юк. Рус мәктәбенең белем бирү сыйфатына тел тидерәсем килми. Башка фәннәр белән бергә, бала анда рус телен дә камил өйрәнә, ләкин бер уңайдан ул рус халкының психологиясен, яшәү рәвешен, менталитетын да үзләштерә, "шул исәптән" еш кына татарларга карата салкынча мөнәсәбәтен дә. Татар рухының нигезен тәшкил иткән моңлы бишек җырлары, туган тел аһәңе, тылсымлы татар әкиятләре бала күңеленнән кысрыклап чыгарыла. Мондый мохиттә татар баласы икенең берсен сайлый: я ул шул мохиткә яраклашып маңкортлаша (күп очракта шулай була), я ул, үзенең милли рухын саклап, шул мохит басымы астында кимсенеп, кысрыкланып яши. Һәр ике очракта да аның күңелендә татар халкына карата тискәре мөнәсәбәт барлыкка килә.

Соңгы берничә дистә ел эчендә халкыбыз өчен афәткә әверелгән катнаш никахларның куркыныч чиккә җитү сәбәбен, беренче чиратта, татар балаларының рус мәктәпләрендә тәрбияләнүеннән эзләргә кирәк. Чөнки ул мәктәпләрдә татарлар һәм руслар арасында моңарчы саклап киленгән бөтен аермалыклар һәм чикләр юыла, киртәләр җимерелә… Нәтиҗә буларак, яшьләрнең динсез һәм денсез бертөрле массасы барлыкка килә.

"Балам татар мәктәбендә белем алса, рус телен белмәс, алга таба укуын дәвам итә алмас", дип хафаланулар нигезсез. Чеп-чи татар авылында үсеп, чиста татар мәктәбен тәмамлап, бүгенге көндә халкыбызның горурлыгы булган дөньякүләм танылган галимнәр, сәясәтчеләр, дәүләт эшлеклеләре күпме! Шул ук вакытта рус мәктәбендә укып, алга таба белем алырга теләмичә, кара эшче булып калган милләттәшләребез дә бихисап. Барысы да кешенең үзеннән, аның тырышлыгыннан тора. Шәһәр җирендә яшәүче балалар рус телен белми калыр, дип борчылу бигрәк тә урынсыз. Бәлки, игътибар итәсездер: татар мәктәп-гимназияләрендә белем алучы кайбер балалар еш кына урамда, хәтта мәктәп коридорларында һәм мәчет залларында да үзара рус телендә сөйләшеп йөри.

Аллаһы Тәгалә без – кешеләрне күптөрле милләтләр итеп яраткан. Аның рәхмәте белән без, татарлар, төрки кавемне тәшкил итәбез, Ул нигъмәт итеп биргән татар телендә сөйләшәбез, Аллаһ биргән хак дин буенча без Аның биргән нигъмәтләрен сакларга тиешбез. Нәселләребезне дәвам итеп, милләтебезне яшәтер өчен, Аллаһ безгә балалар бирә, аларның киләчәген кайгыртуны ата-аналарга йөкли. Һәркем үз балалары өчен Аллаһы Тәгалә каршында җаваплы. Раббыбыз тарафыннан билгеләнгән тәртипкә каршы килеп, балаларыбызны милләтебездән, телебездән, динебездән аермасак иде, аларны да, үзебезне дә җәһәннәм газабына дучар итмәсәк иде!

**Рәшит ФӘЙЗРАХМАН.**
**Түбән Кама шәһәре.**
**beznen.ru сайтыннан алынды**

**Аллага шөкер, динебез җәмгыять тормышына кайта башлаганнан соң, мәчетләребезгә яшьләр күпләп килә башлады. Бу – шатлыклы күренеш, чөнки бүгенге глобальләшү, Көнбатыш культурасына иярү, акчага, тән ләззәтенә табынган, бозыклыкка, әхлаксызлыкка чумып яшәгән җәмгыятебезнең көннән-көн түбәнгә тәгәрәгән заманда аек фикерле, дөрес тормыш рәвеше алып барган дини яшьләрнең булуы киләчәгебезнең өметле икәненә ышаныч уята. Динсез тормышның кая алып барганлыгы барыбызга да билгеле.**

# Бүгенге мөселман яшьләре

Әйтергә кирәк, бүгенге татар мөселман яшьләренең дин тотуы да бертөрле түгел. Гомумән, аларны өч төркемгә бүлеп карарга мөмкин:

● ***беренчеләре*** – иң күп санлы, диннән шактый ерак булган, үзен мөселман дип санаучы, сирәк кенә булса да мәчеткә баручы, кайбер дини йолаларны үтәүче яшьләр;

● ***икенчеләре исә*** – боларның капма-каршысы – дин тотуда асыл ислам диненнән ерак торган, фанатизмга, чикләргә бирелүчеләр. Бу яшьләр үз-үзләрен тотышы, сөйләме һәм гамәлләре белән аерылып тора. Алар күп әйберләрне хәрамга чыгара, үз халкының традицияләренә, гореф-гадәтләренә тискәре карый. Милли бәйрәмнәрне, сәнгать, музыка, гомумән, мәдәниятне тыялар, җәмгыятьтән аерылалар;

● ***өченчеләре*** – уртада баручылар. Болар – традицион ислам юнәлешендәге яшьләр. Алар – диндә ихлас, белемле, гореф-гадәтләрне үтәүче, традицияләрне тотучы һәм җәмгыятьнең киләчәге өчен борчылучы яшьләр.

Бу өч төркемгә бүленгән егет һәм кызларның, бер Аллага, бер кыйблага юнәлеп тә, төрлечә Исламны аңлавы һәм тотуы бик борчулы. Яшьләрнең болай өч төркемгә бүленүе бер яктан табигыйдер, чөнки, миңа калса, бу бүленү һәрвакытта да булгандыр. Иң мөһиме: бүгенге көндә беренче һәм икенче төркемдәгеләр хисабына өченче төркемдәгеләрне күбәйтүдер. Моның өчен дин әһелләренә мөселман һәм дингә керергә әзер булган яшьләргә дөрес дини гыйлем, тәрбия биреп аралаштыру, берләштерү, диндә саклап калу өчен күпкырлы, даими эшчәнлек алып бару зарур. Шунда гына җәмгыятебезнең, милләтебезнең киләчәге якты, өметле булыр. Ник дигәндә, бер галим дә әйткән бит: "Әгәр бер җәмгыятьнең (милләтнең) киләчәген күрергә теләсәгез – аның яшьләренә карагыз!"

**Рәшит МАЛИКОВ,**
**Татарстан Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты аспиранты**



ӘҢГӘМӘ

*Ренат БЕККИН:*

# "ИСЛАМ ТУРЫНДАГЫ СЫЙФАТСЫЗ ӘДӘБИЯТ – МӨСЕЛМАННАРГА ҺӘМ РОССИЯ ҖӘМГЫЯТЕНӘ КАРАТА ҖИНАЯТЬ УЛ"



**Ике-өч ай элек кенә Казанда IV Бөтенроссия ислам китабы ярминкәсе булып үтте. Бер чатыр астына Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан, Уфа һәм Россиянең башка төбәкләре вәкилләре җыелды. Безгә исә "Мәрҗани" нәшрият йортының баш мөхәррире, икътисад фәннәре докторы Ренат Беккин белән әңгәмә оештырып алу мөмкинлеге туды.**


– ***Әссәламегаләйкүм, Ренат әфәнде. "Мәрҗани" нәшрият йортының эшчәнлеге белән таныштырып үтсәгез иде.***

– Вәгаләйкүмәссәлам! "Мәрҗани" нәшрият йорты, шул исемдәге фондның нәшрият бүлеге буларак, фонд булышлыгы белән, фәнни эшчәнлекнең нәтиҗәләрен бастыру максатыннан, 2007 елда нигезләнде. Күпмедер вакыттан соң, хезмәткәрләр тырышлыгы белән, "Мәрҗани" фондының нәшрият бүлеге ислам әдәбиятын махсус чыгаручы нәшрият дәрәҗәсенә күтәрелде.

Нәшриятка ихтыяҗ күптән бар иде. Россиядә берничә әйдәп баручы мөселман нәшрияты бар, ләкин алар арасында ислам дине турында җитди фәнни әдәбият бастыручы бер генә дә академик дәрәҗәсендәгеләре, кызганычка каршы, күренмәде. Бүгенге көндә бездә ислам диненә багышланган фәнни һәм фәнни-популяр булган егерме бишләп китап дөнья күрде. Шуларның яртысыннан артыгы – Россия Фәннәр академиясе институтлары грифы белән чыкты. Авторларыбыз да илебездәге ислам дине буенча әйдәп баручы белгечләр.

Минемчә, динебез буенча фәнни яисә дини китап чыгара торган нәшриятның халтурага хакы юк. Бу – мөселманнарга һәм тулаем Россия халкына карата җинаять. Дөньяда бик күп проблемалар адресатка мәгълүматны тиешле итеп җиткерә алмаудан килеп чыга. Объективлык һәм профессиональлек өчен, сезне хәтта фикерегез белән килешмәүчеләр дә ихтирам итәчәк. Бүгенге көндә Россиядә ислам буенча китапларны тыю модага кереп бара. Дөресен генә әйткәндә, кулымнан килсә, илебездәге дини оешмаларда чыккан ислам диненә багышланган китапларның 80 процентын, профессиональ булмаганнары өчен, тыяр идем. Күп кенә нәшриятларда һәм нәшрият йортларындагы үзләрен мөхәррир һәм корректор дип йөрүче кешеләр эшләренә җавапсыз, бармак аша гына караганга, күп кенә китапларны кулга алырга да оят.

(Ахыры 3 нче биттә.)



### *Мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ:*

# "Ничә дистә еллардан соң Казан шәһәре уртасында зурлап авыз ачарга мөмкинлек туды"

**(Быел Казанда беренче тапкыр республика ифтары узды)**

**26 август көнне Татарстанда беренче тапкыр "Рамазан – 2011" республика ифтары узды. Меңнән артык мөселманны җыйган ифтарны ТР мөселманнары Диния нәзарәте ТР Президенты аппараты, Казан шәһәре хакимияте һәм Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе белән берлектә оештырды.**



Республика дәрәҗәсендәге ифтар оештыруның төп максатларының берсе – дәгъват, хәйрия, бере-берең ә яхшы мөнәсәбәттә булу идеяләрен пропагандалау. "Ифтар – ул ураза тотканнан соң авыз ачу гына түгел, хәйрия, бер-береңнең хәленә керү, мохтаҗларга ярдәм итүнең бер үрнәге дә ул", – дип белдерде оештыручылар.

Мәҗлескә меңнән артык кеше килде: ифтарга мохтаҗ гаиләләр чакырылган иде. Анда шулай ук Иран һәм Төркия консуллары, сәяси җәмәгать эшлеклеләре һәм дин әһелләре катнашты.

Мәҗлес кичке сәгать сигезенче яртыда Кол Шәриф мәчетендә башланып китте. Мөфти Илдус хәзрәт Фәиз Рамазан аеның фазыйләтләре турында сөйләде. Ничә дистә еллардан соң шәһәр уртасында зурлап авыз ачуны оештырырга мөмкинлек тууын, аның тарихи бер вакыйга булуын ассызыклап үтте. "Элек мондый чаралар турында уйлап та булмый иде. Аллаһы Тәгалә безгә сабырлыгыбыз, көн дәвамында ураза тотуыбыз өчен бүләк ясады", – диде ул. Шулай ук республика ифтарының мөселманнар өчен изге Кадер кичендә узуын билгеләп үтте.

Мөфти, ифтарның республика җитәкчелеге фатихасы, Казан шәһәре хакимияте ярдәме белән үткәрелүен әйтеп, аларга рәхмәтен белдерде.

Ахшам намазына азан әйтелеп, авыз ачып, намаз укылганнан соң, ураза тотучылар Меңьеллык мәйданына ифтарга төште. Анда 1200 кешегә өстәлләр, тагын ике мең кешегә Цирк бинасы янындагы машиналарда ланчбокслар әзерләнгән иде. Оештыручылар ифтарга килгән бер кешене дә буш калдырмады.

Ифтар мәҗлесенә килүчеләрне кайнар пылау белән сыйладылар. Моның өчен 120 кг дөге һәм 80 кг ит сатып алынган. Мәҗлесне оештыру өчен, чатырлар корылган һәм аларга ут уздырылган иде. Бу эштә ТР Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, "Татэнергосбыт" оешмасы активлык күрсәткән.

Ифтар мәҗлесен оештыруда катнашкан барлык затларга Илдус хәзрәт рәхмәт белдерде, гаиләләренә иминлек һәм бәрәкәт теләде, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Рәхмәт хатларын тапшырды.

Мәҗлес тәмамлангач, җәмәгать дога кылды. Ифтардан кайтучыларны шәһәр хакимияте биргән автобуслар көтеп тора иде. Ә Кол Шәриф мәчетенә тәравих намазына баручылар, оештыручыларга рәхмәт әйтеп, шунда юнәлде.

**Римма ГАТИНА.**
**tatar-inform.ru сайтыннан алынды**

# ХӘЕРЕҢ БЕЛӘН, ШӘҮВӘЛ АЕ

**(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)**

Мөселман бу айда алты көн өстәмә ураза барлыгын онытмаска тиеш. Бу мәҗбүри булмаса да, пәйгамбәребез галәйһиссәлам үтәгән, безгә дә моны үтәү саваплы икәнлеге хәдисләр белән ачыкланган бер ураза төре. Моның турында пәйгамбәребез (с.г.в.) болай ди: "Кем Рамазан аенда ураза тотса, шуннан соң шәүвәл аеның алты көнен ураза тотса, бер туктамый ураза тоткан кебек булыр (ягъни ел буенча ураза тоткан кебек саналып, шуның әҗеренә ирешер)".

Иң мөһиме: ихлас булып, шушы гыйбадәтне башкарып та без макталырга тиешбез. Ягъни Рамазан аенда бәндәләр, Әлхәмдүлилләһ, барчаларыбыз да бер ай гомеребезне ризыктан, эчемлектән, гөнаһлы гамәлдән тыелып уздырдык. Шушы гамәлебез дәвамлы булсын өчен без бу гыйбадәткә дә көч-куәтебезне куярга тиешлебез. Нәфел гыйбадәт кенә булса да, рәсүлебез (с.г.в.) аны һәрвакыт үтәде (ягъни моны сөннәт мүәккәдә дип алырга кирәк). Шундый сөенеч бирелгән шәүвәл аенда. Аллаһ Раббыбыз шушы мөбарәк шәүвәл айларыбызда да ураза-гыйбадәтләребезне башкарып, барчабызга да бу йөкләтелгән бурычны үтәргә ярдәм итсә иде. Гает көннәрендә исә без барчабыз да бер-беребезне бәхилләп, гафу итеп, туганнар белән арабызны ныгытып, төзек кылып, бер-беребезне рәнҗетүдән сакланып, гает шатлыгын уртаклашыр өчен, зиратка барып, мәетләребезгә дә дога кылып, туганнарыбызны зыярәт кылып уздырырга тиешлебез. Шулай бәйрәм итү – бу мөселманнарга хас булган күренеш. Аллаһ Раббыбызның кодрәте белән Рамазан аенда да ураза гыйбадәтен башкардык, шәүвәл аенда да шушыны дәвам итеп, шатлык-сөенеч белән шәүвәл уразаларын тотарга да барчабызга Аллаһы Тәгалә үзе насыйп әйләсә иде. Әмин!

**Рамил хәзрәт МИҢГӘРӘЕВ,**
**Казандагы "Мәрҗани" мәчете имам-хатыйбы**

# "ИСЛАМ ТУРЫНДАГЫ СЫЙФАТСЫЗ ӘДӘБИЯТ – МӨСЕЛМАННАРГА ҺӘМ РОССИЯ ҖӘМГЫЯТЕНӘ КАРАТА ҖИНАЯТЬ УЛ"

**(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)**

***– Сез – күп кенә академик басма, шәрык һәм гарәпне өйрәнүче күп кенә фәнни хезмәтләр авторы да. Шунысын да билгеләп үтәсе килә: сезнең китапларыгызның автор-төзүчеләре арасында славяннар да аз түгел. Сезнеңчә, ни өчен фәнни-интеллектуаль мохиттә мөселманнар аз?***

– Фамилияләргә генә ориентлашырга ярамый, минемчә. Арапов – кемнең фамилиясе? Ә Сәгадиев? Шидфар? Кирабаев? Боларны дәвам итеп була. Барысы да – безнең авторларыбыз һәм төзүчеләр. Нәшриятның авторлары һәм хезмәткәрләре арасында, сез әйткәнчә, славян фамилияле, исламны кабул иткән руслар да бар. Без авторларны дини принцип буенча түгел, профессиональ яраклылыгы, үз эшенең белгече буенча җәлеп итәбез.

Фәнни-интеллектуаль мохиттә мөселманнарның аз булуы – чыннан да, зур проблема, ләкин моннан егерме, хәтта ун ел элеккеге ситуация кебек үк түгел. 1990 еллар ахырларында күпләр (2006 елда "Мәрҗани" фондын оештыручылар) менә дигән "Мөселман" журналын чыгарды. Аның берничә саны гына чыкты да тукталды. Ни өчен? Чөнки 1999 нчы елдагы укучы фикерле, төпле мөселман журналы өчен әзер түгел иде. Шөкер, бүгенге көндә мондый укучылар бар.

Яхшы дөньяви белемгә ия булган яшь мөселман буыны барлыкка килде. Мөселман зыялылары да бар. Аларның фикеренә, рәсми дин әһелләренекенә караганда, дин тотучылар күбрәк колак сала. Ләкин Россиядә мөселман зыялылары әлегәчә юк. Безнең кайбер нәшриятларыбыз, әйтик, "Дисбе" ("Чётки") кебек, зыялылар катламы булдыруга аз булса да өлеш кертер дип ышанасы килә.

***– Журналда көнчыгыш-ислам тематикасына язучы яңа авторлар бармы, әллә инде күбрәк танылган язучыларның тәрҗемәләрен бастырасызмы?***

– Юк, без исемнәре билгеле булган кешеләрне генә бастырмыйбыз. Безнең өчен яңа исемнәр ачу – бик тә мөһим, журналыбыз талантлы авторларга үзләрен ачарга мөмкинчелек бирә. Баштагы вакытларда бер хезмәттәшем белән бәхәс китте: классика һәм заманча материалларны нинди пропорциядә бирергә? Мин "заманча", яңа караш яклы идем, хезмәттәшем – еллар аша сыналган, тикшерелгән классиклар яклы. Нәтиҗәдә, билгеле бер тигезлек табылды.

***– Хәзерге чор авторларыннан кемнәрне аерып күрсәтер идегез?***

– Аерым алганда, Казахстан язучысы Людмила Фефелованың "А я у тебя в долгу" повестен билгеләп үтәр идем, бу – халыклар дуслыгы турында чын ода, мәдхия. Бенгаль язучысы Хумаюн Әхмәд о Химуның маҗаралы хикәяләр циклын, Борис Сыромятниковның ыру башының узган гасыр башында Якын Көнчыгышка сәфәренә багышланган очерклар циклын да әйтми уза алмыйм. Шулай ук ислам кабул иткән русларның "Гоголь һәм ислам", "Лев Толстой һәм ислам" кебек тематик саннары да кызыклы килеп чыкты, минемчә.

***– 2006 елда сез "Исламский провыв" әдәби премиясенең жюри әгъзасы идегез. Бүгенге өммәтебез өчен мондый төрдәге бәйгеләрнең җәлеп итә торган ягы нидә?***

- Әдәбият – үзебезгә һәм башка дин вәкилләренә дә ислам һәм мөселманнар турында кызыклы итеп җиткерә ала торган мөмкинчелек. Әйтик, Коръәннең иң яхшы тәрҗемәсен дә һәркем укырга әзерлекле түгел, әмма кызыклы романнан бик азлар баш тартыр.

Тәнкыйтьче Лев Данилкинның күптән түгел минем "Ислам от монаха Багиры" романыма язган рецензиясен укыдым. Биредә ул: "Китапны нинди генә мөселман телеканалы да алыштыра алмый", – ди. Менә җавап та соң бу! Без миссионерлык максатлары белән язмыйбыз, безнең максат – дин һәм мәдәниятләр арасында әңгәмә тудырыр өчен күпер булдыру.

***– Бүгенге көндә мөселманнарга үзләренең китабын чыгару кыенмы? Китап кибетләренең киштәләренә китабың менеп утырганчы, нинди этаплар үтәргә кирәк?***


– Динилек монда бернинди дә роль уйнамый. Бүгенге көндә китапны чагыштырмача кыйммәт булмаган бәягә чыгару мөмкинлеге бар. Басма китаплар чыгаручы классик нәшриятлар, әгәр китабың аларның шартларына туры килә һәм кызыклы икән, ике куллап китабыңны алырга риза.

Күп кенә авторлар беренче стадиядә – китапны язгач ук югалып кала. Аны язу гына түгел, нәшриятчыны табу да зарур. Шуңа да йомшаклык күрсәтергә ярамый. Хезмәтең китап киштәләренә менеп утыру белән дә, ягъни үз укучысын тапканчы эш бетми.

Безнең нәшриятка килгәндә, ислам проблематикасына кагылышлы фәнни эшләрне дә, шулай ук матур әдәбият әсәрләрен дә алабыз. Быел "Дисбе" ("Чётки") журналы китапханәсеннән яңа серия башлап җибәрдек. Әлеге сериядә Бетси Шидфарның "Абу Нувас" исемле романы чыкты да инде. Бу – шагыйрьнең роман-биографиясе.

***– Үз проектларыгыз арасында кайсысын уңышлырак дип саныйсыз?***

– "Проект" сүзен бик өнәмим. Бүгенге көндә кая карама, бөтен җирдә проектлар да, проектлар... Минем эшчәнлегемә нинди дә булса нәтиҗә ясау иртәрәк әле, дип уйлыйм. Бары тик билгеле бер уңышларымны билгеләп үтәсем килә: уникаль күренеш дип атап булырлык "Дисбе" ("Чётки") журналын аерып әйтер идем, чөнки ул – Россиядәге беренче мөселман әдәби журналы. Яңа, өйрәнелмәгән өлкәдә һәрвакытта да эшләү кызыклы.




Фәнни эш белән дә шул ук хәл. 1990 нчы еллар ахырында ислам икътисады белән шөгыльләнә башлагач, Россия өчен бу Terra incognita булды. 2001 елда рус телендә "Мөселман хокукында иминиятләштерү: теория һәм практика" дигән ислам финансларына багышланган китабым чыкты. Соңыннан әлеге монография нигезендә диссертация якладым, әлеге китап аша ислам иминияте белән танышкан укучыларым такафул идеясен практикада кулланырга тырышып карадылар. Берсе иреште. Казахстанда. Үзен минем укучы дип санавына шатландым.

Мөгаен, премия, журнал һәм шулай ук фәнни хезмәтләремнән алган иң мөһим һәм кыйммәтле әйбер – яхшы, кызыклы кешеләр белән аралашу булгандыр.

***– Сезгә кайсы якынрак: фән дөньясымы, әллә әдәбиятмы?***

– Бу – минем өчен иң катлаулы сорауларның берсе. Фән һәм әдәбият ике хатынкыз кебек: берсе – зирәк, икенчесе – чибәр. Алар арасында тарткаланасың, газапланасың, ләкин монысын да, тегесен дә ташлый алмыйсың. Җитдирәк якын килсәк, кайдадыр, кайсыдыр ноктада аларның кисешүенә ышанасы килә.

**Ксения САФИУЛЛИНА.**
**islam.ru сайтыннан алынды**
**(Алинә БИКМУЛЛИНА тәрҗемәсе)**

# Төрек Коръән хафизлары Татарстаннан китте

**2011 елның 30 августында Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз Төркиядән Рамазан аена Татарстанга килгән Коръән хафизларга рәхмәт хатлары, истәлекле бүләкләр тапшырды һәм алар белән кичке ашта катнашты.**

Коръән белгечләре Рамазан-шәриф ае буена Татарстанның төрле районнарында тәравих намазлары укыды. Кунаклар мөфти Илдус хәзрәткә, район имам-мөхтәсибләренә ачык йөз белән каршы алып, кунакчыл мөнәсәбәттә булганнары өчен рәхмәтләрен җиткерде. Диния нәзарәте рәисе үзенең сәламләү сүзендә: "Безнең халыкларның уртак яклары күп: мәдәният, тарих, галимнәр... Халыклар арасында дустанә мөнәсәбәтләрне ныгытуда диннең дә әһәмияте үсәр дип ышанам", - дип билгеләп үтте. Төркия республикасының Татарстандагы консулы Әхмәт Акынты киләчәктә дә илләр арасында үзара файдалы бәйләнешләр булачагына ышанычын белдерде.

**dumrt.ru сайтыннан алынды**



# "Мусульманские" исеме астында сатылган пилмәнне ашарга рөхсәт ителәме?

**Марат хәзрәт МӘРДӘНШИН, Татарстан Республикасының көньяк-көнчыгыш төбәге казые:** "Мөселманнарга ашарга рөхсәт ителгән барлык ит продукциясенә дә Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте карамагындагы "Хәләл" комитетының рөхсәте булырга тиеш".

**Мәхмүт хәзрәт ШӘРӘФЕТДИН, Казан шәһәре казые:** "Һәрбер мөселман бәндәсе үзенең нәрсә ашаячагын, нәрсә эчәчәген бик яхшылап карарга тиеш. Чөнки пәйгамбәребезнең (с.г.в.): "Әгәр дә кеше бер йотым хәрам эчсә, бер бөртек хәрам ашаса, аның кырык көн дәвамында гыйбадәте-догасы кабул булмас", дигән мәгънәдә хәдисе бар. Шушы хәдистән нәтиҗә чыгарып без мөселман кешесе үзенең гыйбадәте кабул булсын өчен ашый торган ризыгының хәләл булуын кайгыртырга тиеш дип әйтә алабыз. Шуңа күрә кибеткә барганда, базардан әйбер алганда, сорап булганда хәләлме-юкмы икәнлеген белешү тиешле, этикетлы продукция булганда аның "Хәләл" дигән имзасына игътибар юнәлтергә кирәк. Әгәр дә ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең "Хәләл" комитеты тамгасы юк икән, ул ризыкларны алмаска кирәк. "Мусульманские" исеме астында хәләл булмаган ашамлыклар чыгу очрагы ишәйде. Хөрмәтле мөселман кардәшләребез, игътибарлы булсак иде һәм бу мәгълүматны гади татар мөселманнарына да җиткерсәк иде.

# Аллаһның рәхмәте яусын!




**Без, Казанның Левченко бистәсендә яшәүчеләр, ай буена ураза тотучылар, авыз ачканнан соң, тәравих намазын укучылар, заводта авыр эшләр башкарып, гариплләнеп, пенсиягә чыккан карт-карчыклар исеменнән, шул бистәнең көзгесе булган "Сөләйман" мәчетендә бихисап зур гамәлләр кылучы имам-хатыйб Илдар хәзрәт Баязитов һәм Мәликә абыстай Гыйльметдиновага, шундагы кешеләргә күчтәнәчләр таратучы шәһәребез мэры Илсур Метшинга үзебезнең олуг рәхмәтләребезне белдерәбез. Озакламый миңа 84 яшь тула.**

*Үземнең алтмыш ел гомеремне шушы бистәдә үткәрдем. Мин бистәдә мәчетебез булуга чиксез куану хисләре кичерәм.*

*Хак Тәгаләгә гыйбадәт кылу йорты барлыкка килгәннән соң, бистәдә күп эшләр башкарылды. Мәчеттә Россиянең төрле төбәкләреннән килүче сукырларга, начар күрмәүчеләргә Брайльчә дин сабаклары укытыла, мәктәпләрдә җәйге каникуллар башлануга балаларга ял итү лагерьлары оештырыла. Анда аларга дин тоту кагыйдәләре өйрәтелә, Казанның истәлекле урыннары күрсәтелә. Бу гамәлләр белән Мәликә ханым Гыйльметдинова шөгыльләнә. Гомумән, бистәбездә мәчет гөрләп эшли, Аллага шөкер.*

*Рамазан аендагы тәравихка, җомга намазларына мәчетләребезгә күп кеше йөри. Бигрәк тә яшьләрнең иман йортыбызга тартылуы куандыра. Чөнки киләчәгебез яшьләр кулында.*

*Илебездә киләчәктә дә тынычлык, иминлек дәвам итсен, барлык мәчетләребездә азан авазы яңгырап, кешеләрне намазга чакырып торсын.Ә мәчетнең имамы Илдар хәзрәт Баязитовка, Мәликә Гыйльметдиновага, Казан мэры Илсур Метшинга изгелекләре өчен Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре яуса иде.*

**Зәйтүнә ХӘЙРУЛЛИНА,**
**tatar-islam.ru сайтыннан**

# Җиләк-җимеш турында кызыклы мәгълүматлар

***Хәзерге чор медицинасы җиләк-җимешләрнең, чыннан да, кеше организмына карата шифалы йогынтыга ия булганын, шулай ук күп кенә авыруларны кисәтү өчен хезмәт иткәнен исбатлап күрсәтте.***

Җимешләрнең өлгереп җитү процессы, аларда булган витаминнарның һәм минералларның байлыгы, һичшиксез, кешене тирән уйлануларга этәрә. Фикерләп карагыз, башта гади генә туфрак катламыннан агачлар пәйда була, ә аннары хуш исе, тәме һәм төсе белән бер дә балчык массасына охшамаган җимешләр дә барлыкка килә. Алар җирдән кеше өчен иң кирәкле һәм файдалы минералларны ала да үзләрендә туплый. Аллаһы Тәгалә Җир шарындагы бөтен үсемлекләрнең төсләрен һәм тышкы кыяфәтләрен шуның хәтле эстетик формада булдырды ки, алар шул вакытта ук кеше күңелендә шатлык һәм соклану хисен тудыра. Әлеге үсемлекләр дөньясының сокландыргыч күптөрлелеге безгә шушы искиткеч гомерне бүләк иткән дөньялар Раббысының, Аллаһның иксез-чиксез Зирәклегенә һәм Аның тарафыннан тормышны булдыруның кабатланмас сәнгать икәненә тагын бер шаһит. Безгә исә бирелгән гаҗәеп тормыш матурлыклары өчен бердәнбер Раббыбызга рәхмәтләребезне әйтеп, шушы ямьлелекне күрергә һәм аның турында уйланырга гына кала...

**ТӨЧЕ ЧИЯ АГУЛАРНЫ ЧЫГАРА**

*"Чәнечкесез сәдер (төче чия) агачлары астында"* **(Коръәни-Кәрим: "Вакыйга (Хәл)" сүрәсе, 28 нче аять).**

**ТӨЧЕ ЧИЯ (черешня)** организмны шлаклардан һәм агулардан чистарта. Ул бөерләрнең эшен стимуллаштыра, шунлыктан организмнан җыелып торган сидек кислоталарын һәм урат тозларын чыгару процессын тизләттерә. Шулай итеп, ул ревматизмның, остеохондрозның, тоз утыруның һәм кан тамырлары стеналарының тыгызлануын алга китүен искәртеп куя. Аннан тыш, төче чиядә булган оксиянтар кислотасы бөерләрдә ташларның һәм комның барлыкка килүен кисәтә, ә әгәр дә андый утырмалар инде булса, ул аларның эрүен һәм организмнан табигый юл белән чыгуын тәэмин итә. Төче чия бөерләргә генә түгел, үт куыгы ташларының да чыгуына уңай йогынты ясый. Шулай ук организм өчен зарарлы матдәләрне чыгарып, канны чистарта, димәк, тән тиресен канның пычраклыгы аркасында барлыкка килгән бетчәләрдән сафландыра.

**БАНАН – ҖӘННӘТ ҖИМЕШЕ**

*"Вә җимешләре астан өскә хәтле тезелгән хуш исле банан агачлары арасында"* **(Коръәни-Кәрим: "Вакыйга (Хәл)" сүрәсе, 29 нчы аять).**

**БАНАН** – бик туклыклы продукт, аның 75 процентын су, 1,3 процентын аксым һәм 0,6 процентын май тәшкил итә. Бананның калган өлешен исә төрле углеводлардан һәм калийдан тора.

Банан күп кенә авырулардан савыктыра. Мәсәлән, аны температура күтәрелсә, мускул спазмнары булса, мускул тукымалары зәгыйфьләнсә, ашарга киңәш ителә. Калийга бай булганга күрә, банан организмнан ашкайнату калдыкларының чыгуын тизләтә.

Банан кан басымын төшерергә дә ярдәм итә. Моннан тыш, ул аллергияне дәвалаганда да файдаланыла. Шулай ук бананда булган калий белән натрий берләшмәсе күзәнәкләрнең һәм мускул тукымаларының үсешен стимуллаштыра, йөрәк тибешен һәм су-тоз балансын көйли.

Бананда күп микъдарда B6 витамины бар. Әлеге витаминның организмда җитмәве алҗуга, реакциянең әкренәюенә, тынычсызлыкка, йокысызлыкка, азканлылыкка, бөерләрдә ташларның барлыкка килүенә, тән тиресе халәтенең начараюына, ә авыр стадияләрдә хәтта гакылны җуюга да китерә.

**ЙӨЗЕМ – ВИТАМИННАР ХӘЗИНӘСЕ**

*"Ул су белән сезгә хөрмә, йөзем бакчаларын кылдык, сезнең өчен ул бакчаларда күп җимешләр бар, аларны сез ашыйсыз"* **(Коръәни-Кәрим: "Мөэминнәр" сүрәсе, 19 нчы аять).**

**ЙӨЗЕМ (виноград)** – минераль матдәләргә һәм витаминнарга иң бай җимешләрнең берсе. Аның 20-25 процентын кан тарафыннан бик тиз үзләштерүгә ия булган глюкоза тәшкил итә, шуңа да йөзем авыр физик яки акыл хезмәте белән шөгыльләнүчеләр өчен бик файдалы, чөнки әлеге җимеш мускул һәм акыл алҗуын җиңеп чыгарга булыша.

Йөземдә глюкоза һәм тимернең югары концентрациясе булганга күрә, ул организм тарафыннан кан җитештерелүне арттыра, азканлылыктан дәвалый. Аннан тыш, бу җимештә ашказаны эшләмәгәндә, бөер һәм бавыр авырулары булганда организмга уңай тәэсир итүче табигать компонентлары бар. Бөер эшен активлаштырып, йөзем организмда җыелып торган урат һәм бүтән кислоталар шикелле токсиннарны куып чыгарырга ярдәм итә.

Тикшеренүләр күрсәткәнчә, йөземдә булган кайбер химик кушылмалар яман шеш авыруларының килеп чыгу куркынычын киметә.

**ИНҖИР – МИНЕРАЛЛАРГА БАЙ ЧЫГАНАК**

*"Инҗир җимеше илә ант итәм вә зәйтүн агачы белән"* **(Коръәни-Кәрим: "Тин (Инҗир)" сүрәсе, 1 нче аять).**

**ИНҖИР (инжир)** составында клетчатка, фосфор, кальций, тимер, калий, магний, A, B1, B2, B3, B6 һәм C витаминнары гаять күп. Әлеге минераллар, витаминнар, шулай ук канда тиз эрүчән глюкоза булганга күрә, инҗир авыр физик һәм акыл хезмәте белән мәшгуль булган кешеләрнең көчләрен һәм энергияләрен тиз торгыза. Югары энергетик көч белән берррәттән, инҗир организмдагы мускул һәм нерв системасының үсешен һәм дәвалануын тәэмин итә.

Бөтен җимешләр арасында инҗир минералларга иң бае. Инҗирның күзәнәкчел җепселләрендәге матдәләр кандагы холестерин дәрәҗәсен төшерә. Билгеле булганча, үзләренең рационнарына карата күп итеп клетчатка кулланган кешеләр беркайчан да йөрәк-кан тамырлары авыруларына дучар булмый.

**КОРЪӘНДӘ ХӨРМӘ ТУРЫНДА АЕРУЧА БАСЫМ ЯСАП ӘЙТЕЛӘ**

*"Җир шары төрле кисәкләрдән тора, мәсәлән: бер өлеше су, бер өлеше – игенлек, бер өлеше тау – урманлык вә бер өлеше комлык-сазлык, Аллаһы Тәгалә шулай төзегән вә җимеш бакчалары, игеннәр, икешәрләп вә ялгыз үскән хөрмә агачлары – барчасы бер су белән сугарылалар, ашауда тәме белән берсен икенчесеннән артык кылырбыз. Гакылларын эшләткән кешеләр өчен бу нәрсәләрне яратуда Аллаһның берлегенә, әлбәттә, дәлилләр бар"* **(Коръәни-Кәрим: "Рәгыд (Күк күкрәү)" сүрәсе, 4 нче аять).**

**ХӨРМӘ ҖИМЕШЕ (финик)** 50 процентка якын глюкозадан тора, шуңа да ул бик туклыклы. Ул организм тарафыннан бик тиз үзләштерелә, ә глюкоза нерв киеренкелеген төшерә.

Хөрмә баш мие өчен гаять тә файдалы, чөнки аның 2,2 процентын аксым тәшкил итә. Моннан тыш, анда A, B1 һәм B2 витаминнары да бар. Аксым организм иммунитетын төрле авыруларга һәм инфекцияләргә каршы ныгыта. A витамины күз мускулларын, сөяк тукымаларын һәм тешләрне ныгыта. B1 витамины нерв системасына уңай тәэсир итә. B2 витамины аксымнарны, углеводларны һәм майларны "яндырырга" булыша, шуның белән ул организмны энергия белән тәэмин итә һәм күзәнәкләрне яңарта.

**Харун ЯХЪЯ,**
**төрек галиме**
**(Коръән аятьләренең мәгънәсе Ногмани тәфсиреннән алынды)**

***Илзам ХАҖИЕВ, ТДГПУның II курс студенты (әлеге мәкаләне татар теленә тәрҗемә кылучы):***

– Җиләк-җимешләрне мөмкин кадәр күбрәк ашарга, сәламәтлегебезне ныгытырга кирәк. Ә бу исә, Аллаһы Тәгаләнең ихтыяры һәм фатихасы белән, шушы дөньяда озаграк яшәргә һәм Аңа гыйбадәт кылырга булышыр. Ә инде бакый дөньяга килгәндә, Раббыбызның мәңгелек җәннәтләрендә кешеләргә авыру да, кайгы-хәсрәт тә, курку да янамаячак. Чөнки бу тормышта Аллаһы Тәгаләне бер дип белеп, рухи һәм психологик төшенкелеккә карамыйча, Аңа гына гыйбадәт кылып яшәүчеләр оҗмахта "...җимешләре астан өскә хәтле тезелгән хуш исле банан агачлары [һәм башка, берсеннән-берсе татлы җиләк-җимешләр] арасында" булырлар, алар белән ризыкланырлар (Коръәни-Кәрим, 56:29). Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте чиксез! Аның ризалыгына ирешергә омтылып ашыгыгыз, кадерле дуслар!



# Казанда намаз вакытлары

| Көн | Иртә | Кояш | Зәвәл | Икенде | Ахшам | Ястү | Кыйбла | Көн оз. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 сен | 04:14 | 05:50 | 12:44 | 17:20 | 19:33 | 21:09 | 13:29 | 13:43 |
| 4 сен | 04:17 | 05:52 | 12:43 | 17:18 | 19:31 | 21:06 | 13:28 | 13:38 |
| 5 сен | 04:19 | 05:54 | 12:43 | 17:16 | 19:28 | 21:03 | 13:28 | 13:34 |
| 6 сен | 04:21 | 05:56 | 12:43 | 17:14 | 19:26 | 21:00 | 13:28 | 13:29 |
| 7 сен | 04:24 | 05:58 | 12:42 | 17:12 | 19:23 | 20:57 | 13:28 | 13:25 |
| 8 сен | 04:26 | 06:00 | 12:42 | 17:10 | 19:20 | 20:53 | 13:28 | 13:20 |
| 9 сен | 04:29 | 06:02 | 12:41 | 17:08 | 19:18 | 20:50 | 13:28 | 13:15 |

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №3 (100) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ
**Дизайнер-верстка:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 дәнә. **Заказ:** Е-503
**Газета бушлай таратыла.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
**Бастыруга кул куелды: 2 сентябрь, 12.00 сәгать.**
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан саклаunion!**